По страницам газеты «Коммунизм өчөн» 1960г.

# Сөт алуны арттыру өчен резервларны яхшырак файдаланырга!



*Сез бу рәсемдә Баһау исемендәге колхозның Иске Күл товарлыклы - сөтчелек фермасы сыер савучылары коллективын—җәйге чорда күп сөт өчен ярыш инициаторларын күрәсез.*

*Бу ферма савучыларының сүзләре эштән аерылмый. Җәйнең ике ай ярымында алар һәр сыердан 750шәр килограмм сөт савып алдылар. Августның 15 көнендә һәр сыердан 14әр литр сөт алып, алар бу айда да район колхозлары фермалары арасында беренчелекне тоталар.*

*Уңышның „сере" — савым сыерларын яхшы тәрбияләү һәм туйганчы ашату. Сөт алуны арттыруда төп урынны яшел конвейер тота.*

*—Без үз сүзебезгә ирешәчәкбез,—диләр сыер савучылар.*




★ *Колхоз правлениеләре һәм башлангыч партия оешмалары тәкъдиме белән түбәндәге механизаторлар район Почет тактасына кертеләләр:* ★

**«Урал» колхозы буенча**

15. Фазлыев Тимерхуҗа—комбайнчы, 229 гектар иген урып, 3210 центнер ашлык сукты.
16. Минһаҗев Фәткулла—комбайнчы, 209 гектар иген җыеп, 2942 центнер ашлык сукты.

**Баһау исемендәге колхоз буенча**

17. Нуриманов Хаҗәт —тракторчы, августта 120 гектар туңга сөрде.
18. Мөфтәхов Нур—тракторчы, августта 105 гектар туңга сөрде.

**„Октябрь" колхозы буенча**

19 Әхмәдуллин Тимершәех—комбайнчы, 231 гектар иген җыеп, 2770 центнер ашлык сукты.
20. Ибәтов Ислахетдин—тракторчы, августта 78 гектар туңга сөрде.

☭

М. Әхмәтшин,
Просвет поселогы.

...ларны рекламалау начар оеш-
тырылган, ә кайбер магазин-
нарда хезмәт ияләренә шул

...аңларга тиешләр.

С. Эмиров.

# БЕР ҮЗЕ 500 ГЕКТАР ҖИР СӨРДЕ

Иртәнге тынлыкны двига-
...ь гүләве бозды. Берничә ми-
...тан соң чылбыр тавышы
...етелде һәм боролмадан трак-
... күренде. Бу—Нәсибулла
...ъдәтовның ДТ-54 тракторы
...уга табан бара иде.

...әсибулла сигезенче ел ин-
...трактор йөртә. Бу вакыт
...ндә ул бай тәҗрибә тупла-
...һәм мактауга лаеклы бул-
...

...унсы характерлы, ул баш-
...әрсәгә караганда вакытын
...ок тракторга бүлә. Техни-
... файдалану кагыйдәсен
... саклый.

...әсибулла тракторын ел әй-
...сенә йөртергә тырыша һәм
колхозда төрле эшләрне баш-
кара. Шуңа күрә шушы елның
тугыз аенда аның 448 хезмәт
көне эшләвенә бер дә гаҗәп-
ләнерлек түгел. Ул йомшак
сөрүгә әйләндереп исәпләгән-
дә 510 гектар җир эшкәртте.

Нәсибулла—яңалыкны, ал-
дынгыны яклаучы. Ул Баһау
исемендәге һәм «Октябрь» кол-
хозлары механизаторларының
башлангычларын кайнар як-
лады һәм сентябрьдә 110 гек-
тар туңга сөрергә йөкләмә ал-
ган иде. Тракторчы үз сүзен-
дә нык торды—үз сменасында
115 гектар җир сөрде. Аның
эше агроном тарафыннан ях-
шы сыйфатлы дип кабул ител-
де.


Нәсибулла алмашчылар хә-
зерләүгә дә игътибар итә—
прицепщикларны трактор эше-
нә өйрәтә.

РӘСЕМДӘ: Сәгъдәтов агрега-
ты туңга сөрүдә. Түгәрәк эчен-
дә—тракторчы Н. Сәгъдәтов.

Х. Улимаев.

Г. Бойков фотосы.





*Октябрьны*

*каршылап*

# НАМУСЛЫ ЭШЧӘН



К. Маркс исемендәге колхозның 5 нче бригадасы члены Нигъмәтулла Ялилов намус белән эшли. Ул төрле эшләрне башкара.

Рәсемдә: Н. Ялилов.

Ә. Әхмәтдинов фотосы.

## КОМБАЙН ТӘРТИПКӘ КЕРТЕЛДЕ



«Урал» колхозында комбайнчы Фәткулла Минһаҗев яхшы хезмәт даны алды. Ул ел саен сезон заданиесен үтәп килә. Аның агрегаты 1960 ел сезонында 300 гектар бөртекле культуралар җыйды.

Урып-җыю эшләре тәмамланганнан соң, комбайнчы һәм аның ярдәмчесе Сабир Садрыев комбайнны тазарттылар һәм агымдагы ремонт үткәреп, аны кыш саклауга куйдылар.

—Бу баһаулылар һәм октябрьлыларга безнең җавап. Безнең комбайн 1961 ел сезонына әзер,— ди Фәткулла (уңда).

Сез рәсемдә бу ике дусны эштән соң күрәсез. Шат йөзләре, елмаюлары өстәмә рәвештә аңлатуны таләп итми.


С. Нургалиев.

Г. Бойков фотосы.

## Р САФЫНДА

бөтен бригадалардан да алда

# ИРЕШЕЛГӘННӘР БЕЛӘН ТЫНЫЧЛАНМЫЙ



Лидия Баймурзина „Кызыл Натис“ колхозында савучы булып эшли. Ферманың бу яшь работницасына тана сыерлар беркетелгән. Ул эшли башлавының беренче елында ук һәр сыердан 1432 литр сөт савып алды. Быел Баймурзина 1800әр литр сөт алырга сүз бирде.

Лидия биргән сүзен намус белән үтәде. 1 октябрьга ул һәр сыердан 2006 литр сөт савып алды.

Лидия Баймурзина ирешелгәннәр белән генә тынычланмый. Ел азагына кадәр ул һәр сыердан сөт алуны 2400 литрга җиткерергә булды.

РӘСЕМДӘ: „Кызыл Натис“ колхозы савучысы Л. Баймурзина.

Г. Шәмсетдинов фотосы.

# МЕХАНИЗАТОРЛАР ЭШСЕЗ ТОРМЫЙЛАР



Быел комбайнчы Латыйпов Исламгали яхшы эшләде. Ул үзенең ярдәмчесе Хәммәт Нәҗипов белән Карл Маркс исемендәге колхоз басуларында 420 гектар бөртекле ашлык культуралары урып-җыйды.

Уңыш җыю тәмамлангannan соң, тырыш, хезмәт сөюче комбайнчы башкаларга, районның калган колхозларына ярдәм итәргә теләк белдерде.

Аны „Кызыл Яр“ авыл хуҗалыгы артеленә чакырдылар. Ул монда да кыска гына вакыт эчендә 80 гектар мәйданның уңышын җыйды.

Тәҗрибәле механизатор үзенең сүзен намус белән аклады. Уңыш җыя башлауның беренче көннәрендә Исламгали „СК-3“ комбайнында 350 гектарның уңышын җыярга йөкләмә алган иде. Хәзер аның эш нәтиҗәсе ачык: 500 гектар.

Ләкин урып-җыю эшләре тәмамланганның соңында да Латыйпов эшсез тормый. Ул үзенең комбайнын тәртипкә китерде, аңа тиешле техник тәрбия үткәрде.

27 сентябрьдә ул иртә белән колхоз правлениесенә килде.

— Миңа нинди дә булса эш бирегез әле, — диде ул бригадирга. — Көн бүген шундый матур, кояшлы, вакытны эшсез һич тә үткәрә алмыйм.

Билгеле, аңа эш табылды. Ул 27 сентябрьдә бәрәңге ташуда эшләде. Исламгали бу эшне дә гадәттәгечә намус белән башкарды.

27 сентябрь көне Латыйпов Исламгали өчен аеруча характерлы көн булмады, ә гадәттәгечә, көндәгечә хезмәт көне булды. Ләкин тырыш механизатор үзенең колхозына һәрвакыт ярдәм итәргә тырыша һәм бу көнне дә ул файдалы итеп үткәрде.

**Г. Мөхәммәтов.**

* * *

Рәсемдә: Карл Маркс исемендәге колхозның алдынгы комбайнчысы Исламгали Латыйпов (сулда) һәм аның ярдәмчесе Хәммәт Нәҗипов.

Ә. Әхмәтдинов фотосы.



* Кызу уңыш җыю чорында тракторларның һәм комбайннарның туктаусыз эшләүләрен тәэмин итү өчен ягулыкны вакытында ташу бик мөһим. Менә ни өчен бу чорда Нуриман РТСы шоферы Әхәт Даянов аеруча тырышып эшләде. Ул күп көннәр буена Иглино станциясеннән үзенең ГАЗ—51 автобензовозы белән 4—5 рейс ясады. Көн саен 350—400 километр юл үтеп, ул үзенең машинасына техник тәрбия бирергә дә өлгерде. Шуңа күрә аның машинасы һәрвакыт төзек була.

Рәсемдә: А. Даянов.

Ә. Әхмәтдинов фотосы. *

„Кызыл Натис“, „Урал“, „Октябрь“ колхозларында чөгендер чәчүлекләрен тәрбияләүгә игътибар итмәделәр. Нәтиҗәдә уңыш бик түбән булды.

(Редакцияга килгән хатлардан).



**Яз чәчкәләргә күмелгән иде, ә көз аның „җимешләре“ менә нинди.**

**С. Чистяков рәсеме.**

агрономы.

## *Лафетчы Нурыев*



Лафетлы ургыч машинисты Гайфулла Нурыев Карл Маркс исемендәге колхоз механизаторларының ихтирамын казанды. Ул лафетчы булып икенче ел гына эшли әле. Ләкин шул аз гына вакыт эчендә бай тәҗрибә туплады. Үткән елны ук аның исеме район Почет тактасына кертелде.

Гайфулла быел да югары күрсәткечләргә ирешә-те. Ул һәр көнне 20 гектар мәйданның игенен урды. Ә бодай уруга күчкәч көндәлек норманы 150—160 процентка үтәп барды. Ул 400 гектар мәйданның игенен урырга дигән йөкләмәсен 50 гектарга арттырып үтәде.

—Гайфулла эшкә тотынса җиренә җиткерми туктама[...] —дип колхозда юкка гы[на] сөйләмиләр.

Әйе, лафетчы Нурыев б[...] эштә дә сынатмас.

**Ф. Фәезов,**
колхоз агрономы.

РӘСЕМДӘ: Г. Нурыев бод[ай] ура.

З. Юмашева фотосы.





### ГАЗЕТАНЫҢ ЧИРАТТАГЫ САНЫ

*„Уңыш өчен" стена газетасының чираттагы номерының чыгуы Баһау исемендәге колхоз тормышында зур вакыйга. Ул колхозчылар арасында кызу бәхәс тудыра. Газета укучыларның ихтирамын яулады. Ул системалы рәвештә колхоз тормышын, колхоз производствосының бөтен участокларында да эш барышын чагылдыра. Газета культура һәм көнкүреш мәсьәләләрен, яшьләрнең буш вакытларын ничек үткәрүләрен, культура-агарту учреждениеләренең һәм магазиннарның эшләрен дә игътибарсыз калдырмый.*


*Рәсемдә: колхозчылар „Уңыш өчен" стена газетасының чираттагы номерын укыйлар.*

*Г. Бойков фотосы.*

*...НДА ОТЧЕТ ҺӘМ САЙЛАУЛАР БАРА*

## Партия оешмасы эшенә коммунистларны активрак җәлеп итик

Чушы көннәрдә Красный Ключ ... лышта каралачак мәсьәләләр-



*Быел Баһау исемендәге авыл хуҗалыгы артеле басуларында бөртекле культураларның мул уңышы үстерелде. Басу эшчәннәре уңыш урып-җыюны тизрәк тәмамларга тырышалар. Биредә аеры урып-җыю киң кулланыла.*

*РӘСЕМДӘ (сулда): колхоз басуларында бөртекле культураларны аеры урып-җыю.*

*А. Гаврилов фотосы.*

* * * *

*Быел район колхозларында кукуруз чәчүлекләре 1500 гектарга якын мәйданны били. Калинин исемендәге, Карл Маркс исемендәге, Баһау исемендәге һәм районның башка артельләрендә уңыш аеруча яхшы үстерелде.*

*РӘСЕМДӘ: (уңда) Карл Маркс исемендәге колхозда кукуруз уру.*

*Ә. Әхмәтдинов фотосы.*



*Нуриман РТСының бензин ташучы шоферы Хәмит Минһаҗев бик тырышып эшли. Уңыш җыюның кызу көннәрендә ул Иглин станциясенә 350 километрга якын юл үтеп, өчәр рейс ясый.*

*Яхшы карау һәм сак мөгамәлә итү нәтиҗәсендә, аның машинасы һәрвакыт эшкә яраклы була. Бу аңа колхоз заказлары буенча ягулыкны вакытында, төгәл китереп җиткерергә мөмкинлек бирә.*

*Рәсемдә: Х. Минһаҗев.*

*Г. Шәмсетдинов фотосы.*

1960 ел, 21 декабрь, № 152 (1766)

## Яхшы шофер



буенча 115
...а ала.

**...м транс-**
**...тарифла-**
**халыкның**
**...ларын ка-**

транспорт
...далану та-
...чагыштыр-
1961 ел-
халыкка
...зның кубо-
...роэнергия-
...е 40 тиен
...ул 4 тиен
...репче раз-
...померында
...гәнә әле
урынына
...бачак.
...троллей-
...ларын ка-
...ндый тәр-
...әр шәһәр-
...троллей-
...өчен бер
...эн 15, 45,
...ы тариф-

һәр коллективта, эшне нык сөюче, тыңгысыз характеры, төгәллелеге һәм саклыгы белән аерылып торучы кешеләр күп. Алар вакыт белән дә, ял белән дә исәпләшмичә эшлиләр.

«Октябрь» колхозы шоферы Әһлетдин Фазлыев та шундыйларга керә. Аның машинасы һәрвакыт яхшы торышта һәм ел әйләнәсенә туктаусыз эшли.

—Ул үз машинасындагы җитешсезлекләрне күрергә һәм төзәтергә кайчан өлгерә икән,—дип гаҗәпләнәләр колхозчылар.—Ул туктаусыз эшли бит.

Аның машинасының спидометры 60 мең километрга якын исәпләгән инде, ә бертөрле дә ремонт үткәрелмәгән әле һәм таләп тә ителми.

Үз эшеңне яратуның һәм машинаны һәрвакыт яхшы карауның нәтиҗәсе менә нинди ул!

**И. Фәттахов.**

РӘСЕМДӘ: Ә. Фазлыев.
Г. Бойков фотосы.

*ДЕКАБРЬ ПЛЕНУМЫН КАРШЫЛАП*

# Сыер савучы Фәссәх Хаҗиев



Фәссәх комбайнер иде һәм ул яхшы гына эшләде. Сезон заданиесен һәр елны үтәп килде һәм тәҗрибәле механизатор булып исәпләнде. Ә менә үткән елда яңа квалификация алырга булды һәм... фермага килде—савучы булды. Башта яңа эш аңа буйсынмады. Ләкин Фәссәхнең рухы төшмәде һәм ул алга омтылды. Хатыны Нажия аңа зур ярдәм итте һәм өйрәтте.

Эш мыскыллап көлүләрсез генә бармады. Бигрәк тә ирләр һәм карт хатыннар әче шаярттылар. Имеш, ирләрнең сыер сауганы кайда күрелгән һәм башкалар. Ләкин Фәссәх шаяртулы көлүләрне бер дә искә алмады, ә үзенең күңеле тарткан эшне әкрен генә дәвам итә бирде.

Аның тырышлыгы, омтылышы эштә үзенең нәтиҗәләрен тиз күрсәтте. Өч айдан соң Хаҗиевның фамилиясе Карл Маркс исемендәге колхозның алдынгы терлекчеләре рәтендә иде инде. Менә бу вакытта анардан көлергә һәм шаяртырга беркем дә базмады. Ул ихтирамлы эшчән булып китте.

Яшь савучының нәтиҗәләре шатлыклы. Ул агымдагы елның ун аенда һәр сыердан 2058 литр сөт савып алды да инде. Ә 1960 елгы йөкләмә 2100 литр иде.

—Ноябрь һәм декабрь айларында һәр сыердан тагын кимендә 200 литр сөт алачакмын. Бу исә җидееллыкның икенче елына һәм партия Үзәк Комитетының декабрь Пленумына минем бүләгем булыр,—ди Фәссәх ышанычлы итеп.

Без ул үз сүзен намуслы аклар һәм 1961 елда да сөт савып алуны арттыру өчен ныклы көрәшер дип ышанабыз.

Рәсемдә: Карл Маркс исемендәге колхозның Байгелде комплекслы бригадасының товарлыклы-сөтчелек фермасы савучысы—Ф. Хаҗиев.

**У. Сәгыйтов.**

Г. Бойков фотосы.

## 2540 килограмм сөт алды



Гыйльминур апа Зәйнуллина „Урал" колхозының товарлыклы—сөтчелек фермасында берничә ел инде сыер савучы булып эшли. Ул үзен эшне белүче, тәҗрибәле работница итеп күрсәтте. Иң мөһиме—Гыйльминур апа сөт савып алуны елдан-ел арттыруга ирешә.

1959 елда ул һәр сыердан 2347 килограмм, ә агымдагы елның 10 аенда исә 2540 ар килограмм сөт алды. Ул ноябрь һәм декабрь айларында һәр сыердан 300 килограмм сөт алу өчен көрәшә.

—Безнең эштә бертөрле дә сер юк,—ди Гыйльминур апа.—иң мөһиме—эшне ярату, терлекләрне яхшы карау һәм ашату.

Әйе, апың сүзе дөрес. Сыерның сөте телендә генә түгел, бәлки сыер савучылар кулында да. Моны Гыйльминур апа исендә яхшы тота һәм шуңа күрә дә сөт савып алуны күтәрү өчен бөтен көчен биреп эшли. Алдынгы савучы үз вазифалары белән генә чикләнми. Ул үзенең эш тәҗрибәләрен яшь савучыларга зур теләк белән аңлата һәм аларның ничек гамәлгә ашырылуын күзәтә.

РӘСЕМДӘ: савучы Г. Зәйнуллина.

С.Нургалиев.

Г.Бойков фото...

2019/10

## *Руль артында 19 ел*



Сабира Гарипова трактор белән егерменче ел идарә итә. Ул үз профессиясен елдан-ел камилләштерә барып, „Беларусь" тракторының җитештерүчәнлеген күтәрә. С. Гарипова йомшакка әйләндереп исәпләгәндә 233 гектар урынына 10 айда 411 гектар җир эшкәртте һәм 543 килограмм ягулыкка экономия ясады.

Быел ул кукуруз үстерү звеносы белән җитәкчелек итте. Ул эшкәрткән мәйданның һәр гектарыннан 300 центнердан артык яшел масса алынды.

Хәзер С. Гарипова трактор ремонтлый башлады һәм КПСС Үзәк Комитетының декабрь Пленумы ачылу көненә аны ремонттан чыгарырга сүз бирде.

Н. Мәрданов,

„Урал" колхозы председателе.

РӘСЕМДӘ: тракторчы С. Гарипова.

Г. Бойков фотосы.

...ысын, күтәрелсен!

## Аларга зур ышаныч күрсәтелде

ңгыз
ша-
сәп-
кө-
дә
ол-
ил-
ән
әр-
р-
лә
ш-
ы-
а
к



*РӘСЕМДӘ: XXIII район партия конференциясе делегатлары (сулдан уңга): Баһау исемендәге колхоз председателе* **Х. ХӘСӘНОВ**, *шул ук колхозның сыер савучысы* **Г. ФАЗУЛЛИНА** *һәм Карл Маркс исемендәге колхозның комплекслы бригада бригадиры* **С. ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**


Г. Шәмсетдинов һәм Г. Бойков фотолары.

...ЛАРЫ БӨТЕНХАЛЫК БӘЙР...

...ЛАР БЕЛӘН КАРШЫЛЫЙЛА...

## Бар эшкә дә оста

—Безнең Ну...ислам киң профильле механи...атор, һәр яктан ...да мастер,—ди...әр «Октябрь» колхозында Го...бәйдуллин турында. Һәм чынлап та шулай. Кәер ул, бер төрле дә махсус мәктәп тәмамламасада, ә теләсә нинди авыл хуҗалыгы машинасында да яхшы эшли һәм югары җитештерүчәнлеккә ирешә.



Үткән елларда кукуруз чәчкәндә дөрес квадратлар берничек тә килеп чыкмый иде. Бу культурадан уңыш түбән булды. Колхоз правлениесе иптәш Гобәйдуллинның тырышлыгын һәм эшне төгәл башкаруын белеп, бу культураны чәчүне аңа тапшырды. Ул шунда ук эшкә тотынды. СКГК—6В кукуруз чәчкечен җентекләп ремонтлады һәм көйләде. Аны икенче узлоуловитель белән җиһазландырды. Ычкындыргычның тарту көчен тикшереп чыкты. Болардан соң берничә көн басуда квадратларның дөреслеген сынап карады.

...

булгач, урып-җыю срогы...кә кыскарды. Бу максат... артель лафетлы яңа у... сатып алды. Аны кемгә ы...ып тапшырырга? Тагы... Гобәйдуллинга туктап ...дылар.

Машинаны җыйганда ... яхшы өйрәнеп ул монд... хезмәт үрнәкләре күрс... Тугыз көн эчендә 216 ге... игенне тезмәләргә салды. ... чәчеп үстергән кукурузн... үз вакытында, кыска ср... җыеп алды.

2019/10/29 15:44

Барлык кыр эшләре д...

## Күп балалы аналарны „Ана даны“ орденнары һәм „Ана медале“ медальләре белән бүләкләү турында

# БАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

БАССР Верховный Советы Президиумының 1944 елның 18 август Указы нигезендә СССР Верховный Советы Президиумы исеменнән түбәндәге аналарны бүләкләргә:

### *НУРИМАН РАЙОНЫ БУЕНЧА*

**Җиде бала тудырып тәрбияләп үстергән өчен III дәрәҗә „Ана даны“ ордены белән**

1. Алумбаева Кансепа Изибаевнаны—«Кызыл Натис» колхозы колхозчысы.
2. Атнагулова Пайбукеч Айбулатовнаны—«Родина» колхозы колхозчысы.
3. Гыйрфанова Рәбига Хисаметдин кызын—йорт хозяйкасы, Чандар поселогы.
4. Нурыева Рәхимә Гыйният кызын—Карл Маркс исемендәге колхоз колхозчысы.
5. Сәләхова Гөлсем Миңнегали кызын—Баһау исемендәге колхоз колхозчысы.

**Алты бала тудырып тәрбияләп үстергән аналарны I дәрәҗә „Ана медале“ медале белән**

1. Имаметдинова Тәгъзимә Мөхәмәтгәрәй кызын—Баһау исемендәге колхоз колхозчысы.
2. Исхакова Евдокия Прокопьевнаны—йорт хозяйкасы, Октябрь авыл Советы.
3. Мөхәмәдуллина Зөбәрҗәт Хәйдулла кызын—йорт хозяйкасы, Кировка поселогы.

**Биш бала тудырып тәрбияләп үстергән аналарны II дәрәҗә „Ана медале“ медале белән**

1. Галиәхмәтова Минсафа Рамазан кызын—йорт хозяйкасы, Сарва поселогы.
2. Гыйләҗева Кифая Сәләхетдин кызын—Карл Маркс исемендәге колхоз колхозчысы.
3. Латыйпова Вәгыйзә Галихан кызын—йорт хозяйкасы, Кызыл Яр авылы.
4. Михайлова Татьяна Афанасьевнаны—йорт хозяйкасы, Павловка поселогы.
5. Шәйхинурова Мөкәрәмә Хөбетдин кызын—йорт хозяйкасы, Әтнәш поселогы.
6. Шәйхетдинова Кәфия Арслан кызын—йорт хозяйкасы, Павловка поселогы.

Башкорт АССРы Верховный Советы Президиумы Председателе
**Ф. ЗАГАФУРАНОВ.**

Башкорт АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
**И. ЯРКЕЕВ.**

# Агитатор терлекчеләр янына килде




Баһау исемендәге колхозның агитаторлары яхшы эшлиләр. Алар игенчеләр, терлекчеләр һәм механизаторлар арасында беседалар үткәрәләр һәм кычкырып газета укыйлар

Рәсемдә: агитатор, товарлыклы сөтчелек фермасы мөдире коммунист иптәш Ш. Садрыев сыер савучыларны КПСС Үзәк Комитетының Октябрь Өндәмәләре белән таныштыра.

**Бойков фотосы.**

ХЕЗМӘТ КЕШЕЛӘРЕ

# Колхозчы Мәзһар Солтанов



Мәзһарга 21 яшь. Ләкин ул авыл хуҗалыгы производствосында тәҗрибәле булуы белән дан тота. Ул яшь чагыннан ук хезмәт яратты һәм бригадада бөтен эшне яхшы белә.

—Семья хәле буенча укуны дәвам итәргә туры килмәде. Бәхетне хезмәттә, туган колхозымда табарга уйладым,—дип сөйли Мәзһар Солтанов.

Әйе, яшь колхозчы дөрес юл сайлаган, ул нәкъ менә хезмәттә үзенең бәхетен димәк тормышта үз урынын тапты.

Мәзһар—гади колхозчы, «Родина» авыл хуҗалыгы артеленең өченче комплекслы бригадасы члены. Ул—бөтен эшнең остасы, бригадирның теләсә нинди нарядын үти. Ул кушкан эштән бер генә вакытта да баш тартканы юк. Менә ни өчен аның фамилиясе колхозның Почет тактасыннан төшми, ә үзе бригада членнары арасында һәм бөтен артельдә лаеклы хөрмәт белән файдалана.

Мәзһар тырышып һәм житез эшли. Аны кыенлыклар һәм каршылыклар куркытмый. Аны эш сөйгәне өчен бригада членнары шаярып баһадир дип тә исемлиләр.

РӘСЕМДӘ: Мәзһар Солтанов.

С. Нургалиев.

Р. Мирсаяпов фотосы.



Баһау исемендәге колхоз агитаторы иптәш З. Әбуталипов чираттагы беседага хәзерләнә.

Г. Бойков фотосы.

## Сөт савып алу буенча бригадаларда ярыш йомгаклары

*(1960 елның 10 октябренә, литрларда)*

| урыны | бригадирлар фамилиясе | Колхозлар исеме | ел башыннан алынган сөт | шул исәптән октябрьның 10 көненә |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Асеев | „Кызыл Натис" | 1826 | 46 |
| 2. | Асфин | Карл Маркс исем. | 1824 | 56 |
| 3. | Фәхриев | Баһау исем. | 1791 | 63 |
| | Әхтәмҗанов | Баһау исем. | 1780 | 44 |
| | Гыйльметдинов | Карл Маркс исем. | 1758 | 52 |
| | Зәйнуллин | Карл Маркс исем. | 1715 | 47 |
| | Пантелейко | Киров исем. | 1671 | 49 |
| | Бикбулатов | „Победа" | 1651 | 52 |
| | Җиһангиров | „Урал" | 1637 | 38 |
| | Сөнәгатов | Калинин исем. | 1593 | 43 |
| | Горячев | „Победа" | 1577 | 47 |
| | Шаһитов | „Октябрь" | 1570 | 51 |
| | Исхаков | „Кызыл Натис" | 1518 | 45 |
| | Аскин | Карл Маркс исем. | 1472 | 34 |
| | Мөнәсипов | „Победа" | 1464 | 44 |
| | Подушкин | Киров исем. | 1459 | 37 |
| | Кныш | Киров исем. | 1423 | 38 |
| | Нуретдинов | „Родина" | 1392 | 35 |
| | Әхияров | Карл Маркс исем. | 1345 | 40 |
| | Муллакаев | „Кызыл Яр" | 1321 | 40 |
| | Айбулатов | Калинин исем. | 1295 | 34 |
| | Пойлов | Киров исем. | 1252 | 37 |
| | Зарипов | „Кызыл Яр" | 1109 | 29 |

# БӨЕК ОКТЯБРЬГА — ЛАЕКЛЫ КАРШЫЛАУ!

## СӘЛӘТЛЕ ТРАКТОРЧЫ



„Октябрь“ колхозы тракторчысы Инсафетдин Латыйпов үзен үз эшенең остасы итеп күрсәтте. Ул „Беларусь“ тракторын яхшы өйрәнде һәм аның белән белеп эш итә, теләсә нинди эш башкара, тракторын һәрвакыт төзек тота.

Бөек Октябрь хөрмәтенә хезмәт вахтасына басып, Инсафетдин сезон заданиесен һәм 1960 елга алган йөкләмәсен срогыннан алда үтәде.

Шушы елга кадәр ул „У—2“ тракторында эшләде. Аның „корыч аты“ каршылыксыз эшләде. Ләкин Инсафетдин „Беларусь“ тракторы руле артына утырырга уйлады. Ул үзенең пл угарен тракторчы итеп хәзерләп, „У—2“ тракторын аңа тапшырды, ә үзе резина тәгәрмәчле тракторга утырды.

Сез рәсемдә аның лафетлы ургычны ышаныч белән йөртүен күрәсез.

Ш. Исаев.

Г. Бойков фотосы.

## ОКТЯБРЬГА ХЕЗМӘТ БҮЛӘГЕ

Калинин исемендәге авыл хуҗалыгы артеле членнары быел бәрәңгедән мул уңыш алдылар. Беренче бригада (бригадир иптәш Я. Сөнәгатов) һәр гектардан 110 центнер һәм аннан да артыграк бәрәңге уңышы алынды. Киләсе елда чәчү өчен бәрәңге орлыгы тулысынча салынды. Буртларга 2400 центнер яхшы сыйфатлы бәрәңге салынды. Дәүләткә бәрәңге сату буенча калининлылар үзләренең социалистик йөкләмәләрен уңышлы үтәделәр. Закуп исәбенә алар 620 центнер ур[illegible] бәрәңге саттылар.

Р. Әдиятуллин.



Мәүлет Гайнуллин авыл механизаторы булып уналты елдан артык эшли. Үзенең эшләү дәверендә ул үн меңләгән гектар колхоз җирен сөрде. Хәзер Мәүлет Баһау исемендәге колхозның трактор бригадасында бригадир булып эшли. Аның бригадасы механизаторлары авыл хуҗалыгы техникаларын ремонтлау планын срогыннан алда үтәү өчен көрәшәләр.

Мәүлет — тәҗрибәле механизатор да, яхшы оештыручы да.

РӘСЕМДӘ: М. Гайнуллин.
Г. Бойков фотосы.

По станицам газеты «За коммунизм» 1957 г.